**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 17 июнендәге 2230 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә триатлон буенча Татарстан Республикасы чемпионатын, акватлон буенча Казан шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген, «Казан триатлоны – 2025» республика ярышларын уздыру һәм чараларны әзерләү һәм үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнарга һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы «“Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары нигезендә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, Казан шәһәрендә җиңел атлетиканы популярлаштыру максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәрендә триатлон буенча Татарстан Республикасы чемпионатын, акватлон буенча Казан шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген, «Казан триатлоны – 2025» республика ярышларын әзерләү һәм уздыру вакытына әлеге карарга кушымта нигезендә транспорт чаралары хәрәкәтенә чикләү кертергә:

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр «Миллениум» күперендә (С.Хәким урамыннан Вишневский урамы юнәлешендә хәрәкәтнең ике уң полосасын чикләү);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр «Миллениум» күпере астындагы юл буйлап («Миллениум» күпереннән А.Козин урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр «Миллениум» күпере астындагы юл буйлап (Вишневский урамыннан Подлужная урамына кадәр ике як юнәлеш буенча чыгу юлларында ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Подлужная урамы буенча (Подлужная урамындагы 67 номерлы йорт ягыннан Подлужная урамындагы 78 номерлы йортка кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Вишневский урамы буенча («Миллениум» күпереннән Н.Ершов урамына чыгу юнәлешендә ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Н.Ершов урамы буенча (Вишневский урамыннан чыгу юлыннан алып К.Маркс урамына кадәр, «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексы территориясенә үтәли чыгу (кирәк булганда) һәм электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән хәрәкәтнең уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр К.Маркс урамы буенча (Н.Ершов урамыннан Толстой урамына кадәр, электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Толстой урамы буенча (К.Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Большая Красная урамы буенча [Толстой урамыннан Батурин урамына кадәр, Жуковский һәм Япеев урамнары ягыннан үтәли чыгу мөмкинлеге белән хәрәкәт юнәлешен туктатып тору (кирәк булганда)];

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Батурин урамы буенча (Большая Красная урамыннан Кремль яр буе урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Кремль яр буе урамы буенча (Меңьеллык мәйданына чыгу юлыннан Батурин урамына кадәр хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр автомобиль юлы буйлап (Меңьеллык мәйданы) (Батурина урамына Ташаяк урамыннан чыгу юлында хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Кремль дамбасы буенча (Батурин урамыннан алып С.Хәким урамына кадәр, электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр С.Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан алып «Су спорты төрләре сарае» универсаль спорт комплексы парковкасына кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен дә туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр С.Хәким урамы буенча («Су спорты төрләре сарае» универсаль спорт комплексы парковкасыннан Чистай боҗрасына кадәр, хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр Чистай урамы буенча (С.Хәким урамыннан Ямашев проспекты ягыннан «Ак Барс Арена» стадионы тирәли әйләнеп уза торган юлга чыгу урынына кадәр, бер юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

- 2025 елның 26 июлендә 04:00 дән 16:00 гә кадәр «Ак Барс Арена» стадионы тирәли эчке юл буйлап (ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) әлеге чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.4.1. транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутларын үзгәртү турында хәбәр итәргә;

1.4.2. дистанция маршруты буенча юл билгеләрен урнаштыруда, сүтүдә, япкыч каплау һәм алуда ярдәм итәргә;

1.4.3. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы рәсми сайтында урнаштырырга;

1.4.4. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатолары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә 2025 елның 24 июлендә 20:00 дән 2025 елның 26 июлендә

17:00 гә кадәр әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров):

1.5.1. ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигына төзәтмәләр кертергә, чараны әзерләгәндә килү юлларын һәм транспорт кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чара тәмамланганнан соң, аны уздыру урыннарындагы урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, халыкка мәгълүмат җиткерү өчен яктырту баганаларында юлларны ябу схемаларын урнаштыруны килештерергә;

1.5.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитетына (И.М.Хисмәтуллин) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре белән берлектә, әлеге карарга кушымта нигезендә, йөк техникасы белән юлларны ябу буенча ярдәм күрсәтүне оештырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге чараларны әзерләү һәм уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, Казан шәһәренең алда күрсәтелгән урам-юл челтәре участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеген үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) әлеге чараларда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) спортчылар хәрәкәт иткән вакытта күрсәтелгән участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. **Әлеге карарның** үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөклим.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның 17 июлендәге 2230 номерлы
карарына кушымта




**80 БЕРӘМЛЕК МАХСУС ТЕХНИКА**

______________________